**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 март № 155

г. Казань

Аукцион предметының башлангыч бәясен күтәрү юлы белән үткәрелә торган коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.28 статьясындагы 7 өлеш нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Аукцион предметының башлангыч бәясен күтәрү юлы белән үткәрелә торган коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы түбәндәгеләргә вәкаләтле орган дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион (алга таба – аукционнар) үткәрүгә;

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамәләр, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү хакында шартнамәләр төзүгә;

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле аукционның башлангыч бәясен билгеләүгә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарны кабул иткән көннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә әлеге карарны тормышка ашыру өлешендә тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\155.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 23 март, 155 нче карары белән расланды

Аукцион предметының башлангыч бәясен күтәрү юлы белән үткәрелә торган коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип аукционны үткәрү хакындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән «аукцион адымы»на аукцион предметының башлангыч бәясен күтәрү юлы белән үткәрелә торган коммерциячел файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион, социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзү хокукына аукцион (алга таба тиешенчә – аукцион, шартнамәләр) предметының башлангыч бәясен билгеләү кагыйдәләрен урнаштыра.

2. Аукцион предметының башлангыч бәясен (тиешле шартнамәне төзү хокукына бәяне) билгеләү Татарстан Республикасы милкендә, муниципаль милектә булган яки дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле тиешле шартнамәләр төзүгә вәкаләтле орган булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Аукцион предметының башлангыч бәясе (тиешле шартнамәне төзү хокукына бәя) аукционны үткәрү турында хәбәрнамә бастырылган көнгә кадәр күп дигәндә алты ай алдан, бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән аукцион предметының базар кыйммәтен бәяләүне үткәрү юлы белән билгеләнә.

4. Аукцион предметының башлангыч бәясен (тиешле шартнамәне төзү хокукына бәяне) билгеләү максатларында, вәкаләтле орган дәүләт ихтыяҗларын яки муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәтләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аукцион предметының базар кыйммәтен бәяләүгә шартнамә төзи.

---